ГЛАВА
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «21» июленнән № 28

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппаратының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен раслау турында» 2020 елның 11 ноябрендәге 56 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының 2020 елның 11 ноябрендәге 56 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппаратының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибенә (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.17. пункт өстәргә:

«2.17. Миграция өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозу фактлары турында мәгълүмат булган язма мөрәҗәгать, мөрәҗәгать җибәргән

гражданга аның мөрәҗәгатен яңадан тапшыру турында хәбәр итеп, федераль башкарма хакимият органының эчке эшләр буенча территориаль органына һәм Татарстан Республикасы Рәисенә теркәлгәннән соң биш көн эчендә җибәрелә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Башлык В.М. Козлов